**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

(V чакырылыш)

V чакырылышның II утырышы

**КАРАРЫ**

«07» ноябрь 2025 ел № 14 Урыссу ш.т.б.

Контракт срогы тәмамлануга

бәйле рәвештә Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен туктату турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль законның 22 маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 22.11.2024 ел, № 28 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 51 статьясы белән, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында»гы 07.11.2025 ел, № 13 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләп кую турында»гы 26.10.2020 ел, № 11 карары белән билгеләнгән Самонина Светлана Петровнаның Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен 2025 елның 7 ноябрендә контракт вакыты тәмамлануга бәйле рәвештә туктатырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы

Ютазы район Советы Рәисе                                                                 А.Ә. Шәфигуллин